# ***Сугышка уралган язмышлар…***

Сугыш. Бу сүз күп кенә кешеләр күңелендә аяныч һәм сагыш уята. Чөнки анда аларның әтиләре, абыйлары, ирләре һәлак булган. Исегезгә төшерегез: Бөек Ватан сугышында күпме кеше һәлак булган, күпме кеше туган якларына гарипләнеп кайткан. Күп кенә балалар, аналар шушы сугыш аркасында якыннарын югалтканнар, ятим калганнар.

Сугыш, сугыш... Кемнәрнең язмышына кагылмаган да, кемнәрнең башларына кайгы, күз яше, хәсрәт китермәгән ул. Кешелек дөньясы, сугышлардан ачы сабак алып, җир йөзендә мәңге тынычлык, бәхет өчен көрәшергә тиеш.

...Сугыш ул–14 яшендә ятим калган әбиемнең ачы язмышы да. Аңа 13 яшь булганда, әнисе үлгән була, озакламый әтисеннән дә хәбәр өзелә: кара мөһерле хат кына килә...

1941 нче елда безнең илебезгә фашист гаскәрләре басып кергән. Ул вакытта Ватанны сакларга бөтен халык бердәм булып күтәрелгән. Безнең буынны саклап калган кешеләрнең батырлыгы беркайчан да онытылмас!

Бөек Ватан сугышының тынганына 72 ел вакыт үтте. Мин үзем дә, әти-әнием дә сугыш чорын күрмәдек. Бу канкойгыч сугыш турында ишетеп кенә беләбез. Сугыш дип әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә. Япь-яшь егетләр, кызлар, туган җирләрен саклау өчен, фронтка китәләр. Тылда калганнар да солдатлар өчен җылы оекбашлар, бияләйләр бәйлиләр. Җиңү өчен дип, бар тырышлыкларын куялар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китерә. Я ире, я уллары, я әтиләре Ватан өчен яу кырларында мәңгегә ятып кала. Ачлыктан тилмереп үлүчеләр дә күп була сугыш елларында. Шулай ук фашист концлагерьларында һәлак булучыларның саны да исәпсез. Бу сугышта бик күп якташларыбыз корбан булган. Нинди зур югалтулар!

Ватанны фронтта гына түгел, тылда да саклаганнар. Тылда − кырларда, завод-фабрикаларда эшләүче миллионнарча хатын-кызларның, карт-корының, бала-чаганың батырлыгыннан башка Җиңүне күз алдына да китереп булмый. Шуңа күрә күптәннән инде бу кешеләр дә Бөек Ватан сугышында катнашучылар белән тигезләштерелгән.

Әниемнең әбисе Әхмәтханова Миңнисага сугыш башланганда 13 яшь була.15 яшьлек Миңниса әбине 1943нче елның март аенда, язгы ләчүләр башланганчы дип, Лаеш урманына утын кисәргә җибәрәләр. “Юеш, җепшек кар чабаталарыбызны 1 атна эчендә эштән чыгарды, аякларыбызга киярга булмау сәбәпле такта кисәкләрен юнып, чүпрәк белән бәйләп йөрдек. Өшегән аяклар көндез шырпы кергәнен дә сизми иде, ә кичләрен, сызлаган аякларыбызга мәңге баса алмас кебек тоелды. Ләкин без бирешмәдек, авырттык, егылдык, әмма шунда җыелган 200гә якын үсмернең берсе генә дә эшен ташлап качмады. Барчабызның да якыннарын исән –имин күрәсе килде”, - дип искә ала Миңниса әби.

Миңниса әби исенә төшергән тагын 1 вакыйганы язып үтәсем килә.

...1944нче елның сентяберендә сугыштан 1 аягын тездән югары өздереп Нәкыйп кайтты. Авыл апарасын ерып, исән аягында көч – хәл белән арык гәүдәсен өстерәп баручы Нәкыйп дөньядагы иң матур, иң акыллы егет булып тоелды шулчак. Чөнки ул сугыш афәтеннән гарип калса да, рухы белән көчле иде. Чөнки ул янәшәдә генә һәм... исән иде . Ул вакытта һәркемнең гаиләсе үз кайгысы белән яшәде. Кемдер әтисен, улын, кадерлесен югалткан бу сугышта һәр гаиләнең үз нәфрәте көйде. Үсеп килүче малайлар әниләренең җаны өзгәләнде, алар сугышчылар үстерде.

Кышка өйне җылытырга утын җитмәү сәбәпле, туган – тумача, күрше – күлән берләшә идек дип искә ала Миңниса әби. Һәркемнең дә үз өендә торгызасы килә, чөнки идән астында алтын бәясенә тиң бәрәңге саклана. Ә аны өшетергә ярамый, чөнки ул киләчәк көнгә бердәнбер ышаныч.

Авылдагы кайсы өйнең ишеген какма һәркемнең үз кайгысы була ул чакта. Нәкыйпнең анасы Рәкыйбә көн саен, 2 ел эчендә гарип картка әверелгән 27 яшьлек улына карап көрсенә. Аның иртән караватыннан шуышып диярлек торып китүе, җанын өзгәли ананың. Ә күршедәге Мөхтәрәмә карчык шул Рәкыйбәдән көнләшә. Чөнки аның улы исән, янәшәдә генә, ә менә Мөхтәрәмәнең Харисы инде 4 ай хәбәр бирми. Ичмасам 1 балалары да булмады бит.

82 яшендә китеп барды Мөхтәрәмә әби. Гомер буе Харисын көтеп яшәде. Үлгән дигән хәбәре дә килмәде ичмасам. Нинди генә ячылар какмады Мөхтәрәмә ишеген, чибәр хатын берсен дә кабул итмәде. Ничекләр кертсен ул аларны, аның бит Харисы кайта, әнә бит түбән оч Гайшәнең Габделхагы да 1948нче елда гына кайтты бит. Көтте Мөхтәрәмә, гомер буе көтте.

Авылдагы һәр гаиләнең үз тарихы бар. Ләкин кайсысын гына алма, һәммәсендә сугыш үзенең канлы эзен калдырган.

Ватанны азат итү бөтен халык эше булган. Шуңа күрә "алар Ватанны сакладылар" дигәндә, без ул сугыш еллары халкын – барысын да күз алдында тотарга тиешбез: ул елларда яшәгән, сугышта катнашкан, тылда эшләгән кешеләрне. Аларга мәңгелек дан һәм мәңгелек хөрмәт! Ә безнең бурычыбыз – ул еллардагы халыкның батырлыгын үзебез дә онытмыйча, бездән соң килгән буыннарга да тапшыру.

Сугышлар беркайчан да булмасын иде. Гөрләп туйлар узсын, сабыйлар тусын, барысы да әтиле-әниле үссеннәр! Җирдә матурлык яшәсен! Бары матурлык кына дөньяны афәттән саклый. Шуңа күрә дөньяда яшәүче барлык кешенең бер теләге бар – туган илдә тынычлык булсын!

Мәҗитова Гүзәл Илнар кызы,11 яшь
Балтач районы Чутайавылы